Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 8 октябрь 2019 ел | №149 |

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында» 2019 елның 8 октябрендәге 148 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п. нигезендә, Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында» гы 2019 елның 8 октябрендәге 148 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче һәм II төркем инвалидларыннан һәм өлкәнрәкләрдән (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Җәлил ш.т.п. Ленин ур., Җиңүнең 30 еллыгы, Әхмәдиев урамнарындагы тротуарларны ремонтлау;

- балалар өчен уен мәйданчыкларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, шәһәр тибындагы Җәлил поселогына, Яңа Минзәләбашка яңа уен комплекслары һәм җайланмаларын сатып алу;

- Җәлилдә Сабантуй, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен туклануны оештыру, бүләкләр алу;

- Җәлил поселогы, Габдрахман, Кызыл Бакча, Яңа Минзәләбаш авылларында өстәмә яктырту нокталарын сатып алу һәм урнаштыру;

- Җәлил поселогы, Габдрахман, Кызыл Бакча, Яңа Минзәләбаш зиратларында биек агачларны кисү, үлән чабу, чүп чыгару;

- Дендропарк территориясен һәм Җәлил т. п. бульварын чабу;

- Җәлил т. п. МАФНЫ буяу һәм ремонтлау;

- Җәлил поселогы бульвары территориясендә чүп җыю;

- фонтанга техник хезмәт күрсәтү (электр энергиясе, су өчен түләү, ремонт);

ӘЙЕ ЮК?»

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «PRAVO.TATARSTAN.RU» урнаштырырга һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм «Сарман» газетасында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә. Кәримов